МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

09.08.2024 г. Казань № 639 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәгәндә дәүләт сере булып санала торган мәгълүматлардан файдалана торган вазыйфаларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше, «Россия Федерациясе вазыйфаи затларын һәм гражданнарын дәүләт серен ачу кагыйдәләрен раслау турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 07 февралендәге 132 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе вазыйфаи затларын һәм гражданнарын дәүләт серенә кертү кагыйдәләре нигезендә

БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серенә ия булуны тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган вазыйфаларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының кушымтада бирелә торган исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серенә ия булуга тәшкил итүче вазыйфаларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган мәгълүматларны файдалануга бәйле булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында»14.12.2018 ел, № 1461 од боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Министр И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы боерыгы белән расланды
______________ № ________

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында вазыйфаи бурычларын үтәү дәүләт серенә ия булуны тәшкил итә торган мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган вазыйфаларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары

исемлеге

1. Министр ярдәмчесе
2. Мобилизацион әзерлек буенча әйдәп баручы белгеч
3. Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлеге җитәкчесе
4. Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм юридик эш бүлегенең әйдәп баручы белгече
5. Финанс-икътисад бүлеге җитәкчесе
6. Финанс-икътисад бүлегенең әйдәп баручы белгече
7. Контроль һәм эш алып бару бүлеге җитәкчесе
8. Стратегик планлаштыру һәм фаразлау бүлеге җитәкчесе
9. Фәнни тикшеренүләр, инновацияләр һәм һөнәри компетенцияләрне үстерү бүлеге җитәкчесе
10. Инфраструктура белән тәэмин итү һәм иҗади индустрияләр бүлеге җитәкчесе
11. Проект идарәсе бүлеге җитәкчесе
12. Ресурслар үсеше бүлеге җитәкчесе
13. Ресурслар үсеше бүлегенең әйдәп баручы белгече
14. Беркетмә һәм оештыру тәэминаты бүлеге җитәкчесе
15. Челтәрле хезмәттәшлек, халыкара һәм регионара хезмәттәшлек бүлеге җитәкчесе
16. Челтәрле хезмәттәшлек, халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлек бүлегенең әйдәп баручы белгече
17. Иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү бүлеге җитәкчесе
18. Иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе